**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге составына керүче Рус Кырык Садагы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

21.11.2023 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Рус Кырык Садагы авылында кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү), юлларны ремонтлау өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2023 елның 21 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә 48 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 28 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашкан 28 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге составына керүче Рус Кырык Садагы авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Рус Кырык Садагы авылында кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү), юлларны ремонтлау өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Рус Кырык Садагы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кырык Садак авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________ В.Ф. Шаһиева

Кырык Садак авыл җирлеге
башлыгы ________________ В.Ф. Шаһиева